ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВОЙКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ВОЙКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.06.2018 № 12

Алексеевск муниципаль районы Войкино
авыл җирлеге башкарма комитетының
«Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Войкино авыл җирлеге
муниципаль берәмлегенең
16 февраль, 2017 ел, 4 нче санлы җәмәгать
зиратларын төзекләндерү һәм карап тоту
кагыйдәләрен раслау турында»гы ТР ның
Войкино авыл җирлеге башкарма комитеты
Карарына үзгәрешләр кертү турында

Алексеевск муниципаль районы башлыгының Алексеевск муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары белән үткәргән 09.04.2018 ел, 2 санлы киңәшмә Беркетмәсен үтәү йөзеннән һәм җирлек территориясендә зират территорияләрен төзекләндерүне тәэмин итү максатында

карар бирәм:

1. ТР Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге эчтәлекле 16.02.2017 ел, 4 санлы Карары тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җәмәгать зиратларын төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә:

6 нчы пункт “Зират территорияләрен карау буенча җәмәгать чаралары”н түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“6.1. Зират территорияләрен карау буенча төп җәмәгать чаралары (шимбә, чәршәмбе өмәләре) ел саен җирле үзидарә органнары тарафыннан язгы чорда – апрельнең соңгы шимбәсендә, шулай ук кыш җитәрәк – сентябрьнең соңгы шимбәсендә, шулай ук бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәрдә (Яз һәм хезмәт бәйрәме, Җиңү көне), дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәрдә (Олы көн, Радоница бәйрәмнәре, Ураза, Корбан гаетләре h.б.лар) оештырыла.
Гадәттән тыш һава шартларында (коеп яңгыр, ишеп-ишеп кар яуганда, бозлавыкта h.б.лар) җыештыру-чистарту эшләренең датасы өстәмә рәвештә җирлек башкарма комитеты Күрсәтмәсе белән билгеләнә.
6.2. Җирле үзидарә органнары һәм зиратларга хезмәт күрсәтүче оешмалар җыештыру

кирәк-яраклары һәм махсус техника бирү юлы белән зиратларда шимбә һәм якшәмбе өмәләре үткәрергә булышалар.

6.3. Зират территорияләрен карау буенча җәмәгать чараларын карамакларында әлеге зиратлар урнашкан җирле үзидарә органнары оештыра.

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайты”на “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәргә һәм җирлек сайтына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземә калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе Н.П. Шабутдинова